**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 12 гыйнварыннан № 18

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлегендә
муниципаль берәмлек башлыгының
айлык акчалата бүләкләү,
муниципаль хезмәткәрләрнең
вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру
турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августыннан 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 8 июнендәге 84 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында" карары белән расланган муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының 2018 елның 8 июнендәге 84 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең биләгән вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Ижевского авыл җирлеге
Советы рәисе Н.М.Сергеева